| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

«14» октябрь 2022г. с. Тюлячи № 207

2023 елга Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2022 елның 29 сентябрендәге 01/1851 номерлы һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасының 2022 елның 12 октябрендәге 01-14/142 номерлы хатларын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга расларга:

кушымта итеп бирелә торган Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) Теләче муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының «14»
10 2022 № 204 карары белән
расланган

2023 елга Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга
өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу урыны | Норматив чыгымнар (бер укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өчъеллык укыту срогы | дүртьеллык укыту срогы | бишьеллык укыту срогы | җидееллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |